**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

03.09.2024 970-п

«Транстроймеханизация» ЖЧЖ №1 су алу скважинасының санитар саклык зоналарының гамәлдә булуын туктату турында

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 06.07.2005 ел, № 325 карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, эшчәнлеген туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 17.11.2021 ел, № 1251-п боерыгы нигезендә, 2022 елның 24 февралендәге ТАТ 000220 ВЭ серияле җир астыннан файдалануга лицензияне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. «Транстроймеханизация» ЖЧЖ №1 су алу скважинасының санитар саклык зоналарының гамәлдә булуын туктатырга.
2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Транстроймеханизация» ЖЧЖ №1 су алу скважинасының санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 31.07.2024 ел, № 831-п боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен «Транстроймеханизация» ЖЧЖ җибәрергә.

Министр А.В. Шадриков